МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И
ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘНӘГАТЬҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.12.2024 Казан ш. № 272-ОД

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тотуны яктырту һәм пропагандалау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмә раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 4 декабрендәге 954 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасының энергияне саклауга һәм һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру максатларында,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика бәйгесен үткәрү турында нигезләмә расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тотуны яктырту һәм пропагандалау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмә раслау хакында» 2024 елның 13 февралендәге 26-ОД номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чорда дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында әлеге боерыкны теркәгәннән соң бер эш

көне эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары М.Ф.Миңнебаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы Сәнәгать
һәм сәүдә министрлыгының
05.12.2024 № 272-ОД
боерыгы белән расланды

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тотуны яктырту һәм пропагандалау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмә

Әлеге Нигезләмә массакүләм мәгълүмат чаралары (алга таба – ММЧ) һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Конкурс ел саен «ЭНЕРГОПРОМ» Татарстан энергетика форумын (алга таба – ТЭФ форумы) уздыру кысаларында үткәрелә һәм энергетика, матди, финанс, хезмәт һәм административ ресурсларны нәтиҗәле куллануны яктыртуга һәм пропагандалауга, эшчәнлекнең барлык өлкәләре белгечләренең һәм халыкның энергия ресурсларын нәтиҗәле, энергия ресурсларын саклаучы, табигатьне саклау чараларына карата кызыксынуын үстерүгә һәм саклауга юнәлдерелгән.
1.2. Конкурсны оештыручылар булып Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык), «Татарстан Республикасының Энергия-ресурс нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – «Татарстан Республикасының Энергия-ресурс нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» ДАУ) тора.
1.3. Конкурста катнашуга авторлар, күмәк авторлар яки ММЧ буларак теркәлгән редакцияләр, матбугат хезмәтләре (җәмәгатьчелек белән элемтә бүлекләре) катнаша ала.
1.4. Конкурска Конкурсны уздыру елыннан алдагы елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр басылып чыккан материаллар кабул ителә.
1.5. Конкурс материалларын кабул итә башлау датасы ел саен ТЭФ форумын үткәрә башлау датасына кадәр 42 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән билгеләнә. Конкурс материалларын кабул итүнең тәмамлану датасы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән билгеләнгән ТЭФ форумын үткәрә башлау датасына кадәр 17 эш көненнән дә соңга калмыйча билгеләнә. Агымдагы елда конкурс материалларын кабул итүнең башлану һәм тәмамлану датасы Конкурс уздыру турында хәбәрдә күрсәтелә.
1.6. Конкурсны үткәрү турында белдерү Министрлык сайтында (http://mpt.tatarstan.ru) «Эшчәнлек» - «Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру» «Конкурслар» - «Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм

предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы» бүлегендә конкурс материалларын кабул итү тәмамланганчы 26 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

1.7. Конкурс уздыру турында белдерүдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

конкурс предметы;

номинацияләр, Конкурс материалларын бәяләү нигезләре һәм тәртибе;

Конкурс материалларын кабул итә башлау һәм тәмамлау көне;

Конкурс материалларын тапшыру вакыты һәм урыны;

Конкурс материалларын бирү вакыты һәм тәртибе;

бүләкнең күләме һәм рәвеше;

Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм чорлары;

конкурс материалларын кабул итүне гамәлгә ашыручы затның элемтәгә керү өчен телефон номеры;

Конкурс материалларының исемлеге.

1.8. Конкурс катнашучылар өчен түләүсез нигездә үткәрелә.

## 2. Конкурс номинацияләре

2.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

2.1.1. Татарстан Республикасы предприятиеләренең матбугат хезмәте (җәмәгатьчелек белән элемтә хезмәте) өчен номинация: «Иң яхшы матбугат хезмәте».

Номинациядә предприятиедә энергияне сак тоту һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген арттыру, яңа технологияләр һәм инновацияле алымнар эшләү һәм гамәлгә кертү белән бәйле проектлар карала.

2.1.2. Корпоратив ММЧ өчен номинация: «Иң яхшы корпоратив ММЧ».

Номинациядә корпоратив ММЧ тарафыннан әзерләнгән һәм массакүләм мәгълүмат чараларында энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен актив һәм профессиональ яктырту белән бәйле проектлар карала.

2.1.3. ММЧ өчен номинация (басма матбугат (гәҗитләр, журналлар), мәгълүмат агентлыклары, интернет, электрон, онлайн ММЧ, радио, телевидение, социаль челтәрләр): «Энергонәтиҗәлелек һәм энергияне сак тоту».

Номинациядә массакүләм мәгълүмат чараларында энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен актив һәм профессиональ яктырту белән бәйле проектлар карала.

2.2. Һәр номинация буенча Конкурс материалларын бәяләгәндә таблицада күрсәтелгән бәяләү нигезләре исәпкә алына:

Таблица. Конкурс материалларын бәяләү нигезләре

| № | Номинация | Бәяләү критерийлары | Баллар саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Иң яхшы матбугат хезмәте | компания эшчәнлеген яктырту эшендә тулы күләмдә якын килү | 0 дән 20 гә кадәр |
| | | компаниянең барлык эчке бүлекчәләре белән нәтиҗәле | 0 дән 5 кә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хезмәттәшлек системасы | кадәр |
| | | җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими эшчәнлек кысаларында проект эшчәнлеген гамәлгә ашыру | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | эштә гадәти булмаган һәм иҗади алымнар куллану | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашулар уздыруның даимилеге: матбугат киңәшмәләре, компания җитәкчеләренең әңгәмәләре | 0 дән 5 кә кадәр |
| 2. | Иң яхшы корпоратив ММЧ | мәгълүмат бирү темаларының һәм рәвешләренең төрлелеге: әңгәмәләр, репортажлар, аналитика, фикер алышу материаллары/сәясәтләр, хезмәткәрләрнең сорауларына җаваплар/хезмәткәрләрнең ачык фикере, яңалыклар, конкурслар һ.б. | 0 дән 20 гә кадәр |
| | | ягулык-энергетика комплексы үсеше өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре турында материалларның даими рәвештә чыгуы | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | Материалларны бәян итүнең осталыгы: бәян ителгәннең үтемлелеге, ММЧда рәсми һәм журналист материалларының нисбәте, ММЧ әдәби стиль дәрәҗәсе, ММЧда тәкъдим ителгән темаларның компания хезмәткәрләре өчен актуальлеге | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | басмада/телетапшыруда кулланыла торган материалларның дизайны һәм сәнгатьле бизәлеше/версткасы | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | басманың тиражы/телетапшыруның (корпоратив каналның) аудиториясе /ММЧның компания хезмәткәрләре өчен ачыклыгы: тираж белән компаниядәге гомуми хезмәткәрләр санының нисбәте | 0 дән 5 кә кадәр |
| 3. | Энергонәтиҗәлелек һәм энергияне сак тоту | тиешле номинациядә теманы ачуның осталык дәрәҗәсе: текстларда/репортажларда тәкъдим ителгән белешмәләрнең һәм саннарның объективлыгы, төгәллеге, нәтиҗәләрнең һәм фаразларның нигезлелеге/дәлилләнүе | 0 дән 20 гә кадәр |
| | | номинациянең темасы буенча эшнең даимилеге, дәвамлылыгы | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | мәгълүмати материаллар юнәлдерелгән аудиториянең киңлеге | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | эшне башкаруга иҗади якын килү | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | Татарстан Республикасы халкы өчен тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте | 0 дән 5 кә кадәр |
| | | Һәр номинация буенча гомуми баллар саны | 40 |

## 3. Конкурска материаллар бирү һәм аларны рәсмиләштерү тәртибе

3.1. Конкурс материаллары рус һәм татар телләрендә башкарылырга мөмкин.

3.2. Конкурс материаллары түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза һәм әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән проект паспорты;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче һәм 4 нче кушымтасындагы рәвешләрдә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен).

3.3. Конкурс материаллары әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

3.4. Конкурс материаллары Министрлыкның электрон почта адресына электрон рәвештә бирелә: cetrt@mail.ru.

3.5. Гариза Министрлыкка кергән көнне электрон рәвештә теркәлә.

3.6. Тәкъдим ителгән конкурс материалларының әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге һәм әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы таләпләренә туры килмәве ачыкланган очракта, Министрлык, конкурс материалларын теркәгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган бер көнлек чорда катнашучыга гаризада күрсәтелгән электрон адрес буенча, тәкъдим ителгән конкурс материалларын эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көнлек чорда өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында хәбәр итә.

Әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге һәм әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта таләпләренә туры килмәгән конкурс материаллары кабат тәкъдим ителгән очракта, эш Конкурска кертелми.

Министрлык яңадан тапшырылган конкурс материалларын теркәү көненнән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган бер көнлек чорда, катнашучыга гаризада күрсәтелгән электрон адрес буенча әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге һәм әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы таләпләренә туры килмәве сәбәпле, конкурс материалларын кире кагу турында хәбәр итә.

Министрлык түбәндәге очракларда конкурста катнашуга кертүдән баш тарта:

гариза бирүче «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия.

## 4. Конкурс комиссиясе. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

4.1. Конкурсны үткәрү өчен Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе төзелә, ул рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясенең саны алты кешедән дә ким була алмый.

Конкурс комиссиясе, әгәр аның утырышында әгъзаларының гомуми санының кимендә 50 проценты катнашса, карарлар кабул итәргә хокуклы була.

4.2. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышларда рәислек итә, аның эшен оештыра, аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота. Конкурс комиссиясе рәисе булмый торган чорда аның вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

4.3. Конкурс комиссиясе түбәндәге вазыйфаларны башкара:

Конкурска тәкъдим ителгән конкурс материалларын карый;

Конкурс материалларын әлеге Нигезләмәнең 2.2 бүлегендә күрсәтелгән нигезләр буенча бәяли;

Конкурска йомгак ясый.

4.4. Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурска тәкъдим ителгән конкурс материалларын карау нәтиҗәләре буенча һәр номинация буенча бер җиңүче (1 урын) билгеләнә.

Тиешле номинация буенча бер генә катнашучы заявка биргән очракта, әлеге номинациядә конкурста җиңүче билгеләнми.

4.5. Конкурс нәтиҗәләре буенча карар чыгару буенча Конкурс комиссиясе утырышы турыдан-туры/читтән торып үткәрелә.

Министрлык Конкурста катнашучылардан Конкурс материалларын кабул итү тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә аларны Конкурс комиссиясе әгъзаларына җибәрә.

Конкурс комиссиясе әгъзалары, Конкурста катнашучыларның тәкъдим ителгән Конкурс материалларын карап чыгып, аларны алганнан соң ике эш көне эчендә, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийларына ярашлы рәвештә баллар биреп, Конкурс материалларының үз бәяләрен Министрлыкка җибәрәләр.

Министрлык Конкурс комиссиясе әгъзаларыннан Конкурс материалларын бәяләүне алган көнне:

Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан һәр номинация буенча җиңүчеләрне билгеләп, Конкурс материалларына бирелгән бәяләрнең җыелма таблицасын төзи;

Конкурс комиссиясе карары проектын әзерли һәм аны, раслау өчен, Конкурс комиссиясе рәисенә җибәрә.

Конкурста җиңүчеләр Конкурста катнашучы җыйган балларны кушу юлы белән билгеләнә.

Һәр номинациядә иң күп балл җыйган катнашучы Конкурста җиңүче дип танылa.

Конкурста катнашучы берничә кешенең җыйган баллар саны бер үк булса, турыдан-туры тавыш бирү игълан ителә. Карар утырышта катнашкан Конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.6. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Министрлык карар проектын Конкурс комиссиясе рәисенә тәкъдим иткән көнне Конкурс комиссиясенә рәислек итүче зат тарафыннан расланa.

Конкурс комиссиясе беркетмәсе Министрлык сайтында (http://mpt.tatarstan.ru) «Эшчәнлек» - «Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру» «Конкурслар» - «Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы» бүлегендә аны раслаган көнне урнаштырыла.

4.7. Конкурста җиңүчеләр истәлекле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә. Конкурс нәтиҗәләре буенча призлы урын алган, «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Конкурста катнашуга

кертелгәннән соң чит ил агенты дип танылган катнашучы истәлекле призлар һәм дипломнар белән бүләкләнми.

4.8. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру йомгакларын карау турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте утырышы кысаларында үткәрелә.

## 5. Конкурсны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

Конкурсны финанслау ТЭФ форумын уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

форма

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында катнашу өчен гариза

1. Катнашучы турында белешмәләр

| | |
|---|---|
| Оешманың атамасы | *Искәрмә: Кыскартылмаларсыз тулы атаманы күрсәтергә.* |
| Эшчәнлек өлкәсе | |
| Почта адресы | |
| Юридик адресы | |
| Оешма җитәкчесенең (баш мөхәррирнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасы | |
| Оешманың телефоны, e-mail, веб-сайты | |
| Конкурста катнашу буенча элемтәгә керү өчен зат (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм e-mail) | |

2. Тапшырыла торган эш турында белешмәләр

| | |
|---|---|
| Проектның исеме | |
| Конкурс номинациясе категориясе | *Искәрмә: Номинация категориясенең исеме Конкурс турындагы нигезләмәнең 2 бүлегенә туры килергә тиеш* |
| Конкурс номинациясе | *Искәрмә: Конкурсның исеме Конкурс турындагы нигезләмәнең 2 бүлегенә туры килергә тиеш* |

3. Заявкага беркетелә торган документлар исемлеге:

| № | Документлар исемлеге (битләр саны/данә) |
|---|---|
| *1* | *Мәсәлән: Паспорт (5 бит)* |
| *2* | *Мәсәлән: Тәкъдирнамә (10 бит)* |
| *3* | *Мәсәлән: Фотолар (3 данә)* |
| *4* | *Мәсәлән: Видеоролик (1 данә)* |

4. Хәзергесе белән раслыйм:

массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тотуны яктырту һәм пропагандалау, энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча республика конкурсына тәкъдим ителгән конкурс

эшләрендә өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын боза торган материаллар юк;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып саналмыйм.

*Оешма җитәкчесе* ________________________________ _______________

Вазыйфа Имза (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

*Мөһер*

*Конкурска җибәрү көне:*_______________________

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсының конкурс материалларын рәсмиләштерүгә карата таләпләр

1. Конкурс материаллары электрон рәвештә «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» ДАУның мәгълүмати-нәшрият һәм мәгариф эшчәнлеге бүлегенең электрон почтасы адресына җибәрелә: cetrt@mail.ru.

2. Барлык логотиплар, фоторәсемнәр һәм башка рәсемнәр аларны JPG рәвешендә бастырып чыгару (кимендә 300 dpi) мөмкинлеген бирә торган булырга тиеш. Шул ук вакытта һәр аерым документ (гариза, тәкъдирнамә һ.б.) аерым битләргә бүленмичә, бердәм файл итеп рәсмиләштерелә *(Искәрмә: бер документның барлык битләре дә бер файлда булырга тиеш).*

3. Гариза оешманың вазыйфаи заты (директор, директор урынбасары яки вәкаләтле зат) тарафыннан имзалана.

4. Гаризага кушымта итеп бирелә торган паспорт түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

4.1. «Иң яхшы матбугат хезмәте» номинациясе өчен паспорт:

кыскача эчтәлек – матбугат хезмәте (җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге) эшчәнлегенең кыскача тасвирламасы һәм бурычлары;

компаниянең матбугат хезмәте (җәмәгатьчелек белән элемтә хезмәте) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

матбугат хезмәте (җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге) хезмәткәрләре саны;

энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру тематикасы буенча матбугат хезмәтенең (җәмәгатьчелек белән элемтә хезмәтенең) эш юнәлешләре;

ММЧ һәм компания эшчәнлеге турында мәгълүмат алу белән кызыксынучы төрле җәмгыять төркемнәре белән эшләү структурасының һәм алымнарының кыскача тасвирламасы (шул исәптән матбугат турлары, матбугат киңәшмәләре буенча мисаллар һ.б.).

Теркәргә кирәк: матбугат хезмәтенең (җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегенең) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру тематикасы буенча һөнәри осталыгын күрсәтүче иң кызыклы басма, видео- һәм башка материаллар мисалларын.

4.2. «Иң яхшы корпоратив ММЧ» номинациясе өчен паспорт:

ММЧ атамасы;

ММЧ төре: басма, электрон, телевизион;

ММЧ нигез салу елы;

басманың тиражы (басма ММЧ өчен) һәм чыгу ешлыгы;

кыскача эчтәлек: ММЧ бурычларын кыскача тасвирлау һәм ММЧ нинди аудиториягә юнәлдерелгән. Басманың үзенчәлеге нәрсәдә, материаллар әзерләүдә һәм ММЧ чыгаруда нинди гадәти булмаган алымнар (булган очракта) кулланыла.

төп бүлекләр, темалар һәм бүленешләр;

күмәк авторлар: чыгарылышларны әзерләү өчен кем җәлеп ителгәнен тасвирларга (компаниянең PR-хезмәте/матбугат үзәге хезмәткәрләре, башка бүлекләрнең хезмәткәрләре, чит журналистлар/компанияләр);

компаниянең корпоратив сайтында ММЧ битенең, шулай ук социаль челтәрләрдә ММЧ битләренең (булган очракта) jpg рәвешендәге сурәтләре. Сурәтләр (рәсемнәр) файл эчендә эш паспорты белән урнаштырыла.

Беркетергә кирәк:

басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары өчен – бер чорда биш басмадан артмаган сканнар

1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр, энергияне саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру тематикасы буенча конкурс уздырылганчы, (PDF форматында);

телевидение тапшырулары өчен – Rutube, YouTube сылтамалар.

4.3. ММЧ өчен «Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм энергияне сак тоту» номинациясе өчен паспорт:

ММЧ атамасы;

ММЧ төре;

тарату (күрсәтү) төбәге, тиражы (басма ММЧ өчен) һәм ММЧның төп аудиториясе;

конкурсны үткәрү елы алдыннан килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр тапшырыла торган конкурс материаллары кысаларында ММЧда бастырып чыгарылган (эфирга чыгарылган) материаллар саны;

конкурс материаллары темасы буенча мәкаләләрнең (видеосюжетларның) төп авторлары;

Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән номинациясен бәяләү нигезләре буенча өстәмә мәгълүмат.

Беркетергә кирәк:

энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру тематикасы буенча Конкурс уздыру елыннан алда килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр ММЧ басылып чыккан (эфирга чыккан) мәгълүмати материалларның мисаллары (PDF рәвешендә);

басма материаллар өчен – PDF рәвешендә дүрт-биш мәкаләнең сканы;

телевизион сюжетлар өчен – Rutube, YouTube каналында материаллар урнаштырылган, алар буенча Конкурс комиссиясе әгъзалары видеосюжетларны карый ала торган сылтамалар.

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин ,____________________________________________________________,
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), тулысынча

вәкил ______________________________________________________,
оешманың атамасы

элемтә өчен телефон: ____________________,

«Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (Казан шәһәре, Академик Губкин урамы, 50, 1001 бүлмә) (алга таба – Оператор), Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү кысаларында, шулай ук конкурста катнашучыларның мәгълүматлар базасын булдыру, Оператор сайтларында (httt://tef.tatar.ru) конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат урнаштыру һәм конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат урнаштыру максатында, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә автоматлаштыру чараларын кулланып, кулланмыйча да, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге гариза белән Операторга түбәндә санап үтелгән шәхси мәгълүмат категорияләренә караган минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә рөхсәт бирәм:

1. Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)
2. Элемтә өчен телефоны
3. Эш урыны
4. Вазыйфа
5. Затның төсле цифрлы фотография сурәте

Мин шәхси мәгълүматларны бары тик түбәндәге максатларда гына куллануга ризалык бирәм:

– «Без энергонәтиҗәлелекне сайлыйбыз» яшь инициативалар республика конкурсында катнашу өчен гариза төзү һәм эшкәртү;

– тапшырылган конкурс материалларын карау;

– статистика алып бару;

– конкурс нәтиҗәләрен Операторының рәсми сайтында бастырып чыгару;

– югарыда күрсәтелгән максатларга бәйле башка гамәлләр.

«Без энергонәтиҗәлелекне сайлыйбыз» яшь инициативалар республика конкурсы турындагы мәгълүматны бастыру кысаларында, басма матбугатта, интернет челтәрендә, радио- һәм телевидение эфирында урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материалларда үз сурәтләремне кулланырга ризалык бирәм.

Сурәтләр минем намусымны, абруемны һәм эшлекле дәрәҗәмне боза торган ысуллар белән кулланыла алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык вакыты бирелгән мизгелдән башлап чикләнмәгән вакытка гамәлдә була һәм, Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп, Операторга гади язма рәештә гариза биргән очракта, минем тарафтан кире алынырга мөмкин.

"___" _________20___ ел. ____________________ ________________

(имза) Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,______________________________________________________________________________,
Шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

элемтә өчен телефон: _____________________, электрон почта адресы _____________________,

«Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (ИНН 1654029730, ОГРН 1021602848519, уздыру урыны: Казан шәһәре, Академик Губкин урамы, 50, 1001 нче бүлмә)(алга таба – Оператор), Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү кысаларында, «ЭНЕРГОПРОМ» Татарстан энергетика форумының рәсми сайтында минем турында мәгълүмат урнаштыру максатында, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны түбәндәге тәртиптә эшкәртүгә риза булуымны белдерәм:

| Шәхси мәгълүматлар категориясе | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Тарату өчен рөхсәт итәм (әйе/юк) | Затларның чикләнмәгән даирәсенә тарату өчен рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Ата исеме (булган очракта) | | | | |
| | Элемтә өчен телефоны | | | | |
| | Эш урыны | | | | |
| | Вазыйфа | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Затның төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары Оператор тарафыннан затларның чикләнмәгән даирәсенә тапшырылачак һәм алар белән башка төрле гамәлләр кылыначак мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән эш итү |
|---|---|
| http://tef.tatar | Затларның чикләнмәгән даирәсенә бирү |

Әлеге ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә бирелде һәм 20___ елның «__» _________ башлап 20 ___ елның «__» _________ кадәр гамәлдә булачак.

Минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктату турында таләп итү хокукын үз өстемдә калдырам. Таләпне алган очракта, Оператор минем шәхси мәгълүматларымны таратуны кичекмәстән туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

_______________ _______________________ _______________________
дата имза Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)